КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 май г.Казань № 376

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 июнендәге 176-ФЗ номерлы Федераль законны Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2015 ел, 28 сентябрь, 717 нче карары үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 29 май, 429 нчы; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 828 нче; 2015 ел, 29 июль, 550 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 997 нче; 2017 ел, 13 июль, 494 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2019 ел, 17 сентябрь, 839 нчы; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче; 2021 ел, 10 апрель, 236 нчы; 2021 ел, 27 декабрь, 1303 нче; 2022 ел, 11 март, 214 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы, 2024 ел, 1 февраль, 53 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә, 8 пунктның сигезенче абзацында «(стипендияләр һәм башка түләүләр)» сүзләрен «, ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән

мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга ай саен өстәмә түләү» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие бирү турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 26 декабрь, 120 нче; 2020 ел, 17 апрель, 304 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче; 2021 ел, 10 апрель, 236 нчы; 2022 ел, 28 гыйнвар, 66 нчы; 2022 ел, 24 май, 484 нче; 2022 ел, 14 декабрь, 1325 нче; 2023 ел, 4 февраль, 100 нче, 2023 ел, 16 октябрь, 1313 нче, 2024 ел, 1 февраль, 53 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие бирү тәртибенә, 6 пунктның дүртенче абзацында «стипендияләр, матди ярдәм» сүзләрен «ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга ай саен өстәмә түләү» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү турында» 2019 ел, 3 декабрь, 1095 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 28 декабрь, 1234 нче, 2023 ел, 4 февраль, 100 нче, 2023 ел, 16 октябрь, 1313 нче, 2024 ел, 01 февраль, 53 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлешендә каралган Дару чараларын һәм даруханә ассортиментының башка товарларын сатып алуга түләү билгеләгәндә гаиләнең бер кешегә исәпләнгән уртача керемен исәпләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) хезмәт яисә башка вазыйфаларны башкарган өчен бүләкләү, стимуллаштыру характерындагы түләүләрне кертеп, граждан-хокукый шартнамә кысаларында башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен, гамәлләр кылган өчен бүләкләү, шул исәптән түләүле шартларда опека яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турындагы шартнамә (тәрбиягә алган гаилә турында шартнамә, патронат гаилә турында шартнамә) буенча, урнашкан (идарә) урыны Россия Федерациясе булган Россия Федерациясе салым резиденты оешмасының (Директорлар советының яисә мондый органның) директорларны бүләкләү һәм идарә органы әгъзалары ала торган башка шундый ук түләүләр, бу затларга йөкләнгән идарә вазыйфалары фактта башкарылган яки күрсәтелгән бүләкләү түләнгән урынга бәйсез рәвештә, түбәндәгеләрдән тыш:

Яшьләре «Аларны аз керемлеләр дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен гаиләнең җан башына уртача керемен һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпкә алу һәм исәпләү тәртибе турында» 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясында каралган исәп-хисап чорында

18 яшьтән кимрәк тәшкил иткән һәм күрсәтелгән чорда гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында һәм (яисә) көндезге уку формасы буенча югары белем бирүче мәгариф оешмасында, өстәмә белем бирү программалары буенча гына кимендә 6 ай укыганнар укудан тыш, балалар алган бүләкләр;

Россия Федерациясе законнары нигезендә эш бирүче аша салым түләвенә хокук алуга бәйле рәвештә физик затлар керемнәренә кире кайтарылган салым, шулай ук салым чоры тәмамланганнан соң салым тотып калуларын исәпкә алып, салым базасын яңадан төзегәннән соң кире кайтарылган акчалары суммасы;»;

«б», «з», «и» пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

«к» пунктчасында:

дүртенче абзацка «, халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте органнары тарафыннан түләнә торган ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга ай саен өстәмә түләү» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

ундүртенче абзацта «эшләмәүче» сүзен төшереп калдырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 март, 129 нчы; 2021 ел, 24 май, 365 нче; 2021 ел, 15 ноябрь, 1076 нчы; 2022 ел, 5 декабрь, 1286 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы; 2023 ел, 31 июль, 913 нче, 2023 ел, 16 октябрь, 1313 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балалар кирәк-яракларының бүләк комплектын алу хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме күләмен исәпләү һәм гаиләнең җан башына уртача кереме күләме хакындагы белешмә кәгазен бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның өченче абзацында «исемлекнең 1 пунктындагы «в» пунктчасында, «д» пунктчасының өченче - дүртенче абзацларында, «е» пунктчасының өченче абзацында, «ж» пунктчасының алтынчы - җиденче, тугызынчы абзацларында күрсәтелгән» сүзләрен «исемлекнең 3, 4, 6, 7, 14 - 16 пунктларында күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның дүртенче абзацында «стипендия, матди ярдәм» сүзләрен «ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга ай саен өстәмә түләү» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Энергия кабул итүче җайланмаларны ташламалы шартларда челтәр оешмасы белән технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү өчен гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача керем күләме турында белешмә бирү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2022 ел, 15 декабрь, 1333 нче карары белән расланган Энергия кабул итүче җайланмаларны ташламалы шартларда челтәр оешмасы белән технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү өчен гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача керем күләме турында

белешмә бирү тәртибе хакындагы нигезләмәгә, 2.3 пунктның дүртенче абзацында «стипендия, матди ярдәм» сүзләрен «ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга ай саен өстәмә түләү» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 июнендәге 176-ФЗ номерлы Федераль законны Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2015 ел, 28 сентябрь, 717 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин